Р Е С П У Б Л И К А
Т А Т А Р С Т А Н

С О В Е Т  Т И М Е Р Ш И К С К О Г О
С Е Л Ь С К О Г О  П О С Е Л Е Н И Я
С А Б И Н С К О Г О
М У Н И Ц И П А Л Ь Н О Г О   Р А Й О Н А

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

Т А Т А Р С Т А Н  Р Е С П У Б Л И К А С Ы

С А Б А   М У Н И Ц И П А Л Ь
Р А Й О Н Ы
Т И М Е Р Ш Ы К  А В Ы Л  Җ И Р Л Е Г Е
С О В Е Т Ы

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер  урамы,  19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

24.09.2018 г. — № 21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Тимершык авыл җирлегендә гражданнардан үзара
салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле
референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 № 67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 № 23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Тимершык авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендә 20 номерлы “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Тимершык авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 20 сентябрендә 41 п номерлы “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Тимершык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Тимершык авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Кызыл-Мишә авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Көек авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
- Миңгәр авылында күмү урыннарын карап тоту;
- Сабай авылында күмү урыннарын карап тоту.

ӘЙЕ — ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Тимершык авыл җирлеге башлыгы — А.Х. Хаҗиев